МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2023 Казан ш № 779

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 4 октябрендәге 779 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.06.2016 №337, 26.09.2018 №904, 05.03.2019 №158, 07.05.2019 №330, 14.11.2019 №1019, 29.06.2020 №468, 08.10.2020 №713, 13.10.2021 №756, 04.10.2022 №908, 30.06.2022 №651, 26.01.2023 №41, 23.06.2023 №501 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент) Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 №328, 14.11.2019 №1018, 31.03.2020 №216, 23.06.2020 №454, 08.10.2020 №713, 20.10.2021 №773, 09.08.2022 №766, 28.09.2022 №896 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.